КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 сентябрь г.Казань № 738

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 ноябрь, 1230 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 ноябрь, 1230 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 декабрь, 1338 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 декабрь, 910 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы гамәлгә ашыру кысаларында чаралар үткәрү;»;

11 пунктның икенче абзацында «һәм ярдәмче программа» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

«20. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты субсидия бирү һәм субсидияләр бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгалар (контроль нокта) нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү мониторингын Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә уздыра.».

2. Бу карар (бу карарның 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы алтынчы абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин